ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы
Суыксу авыл җирлегенең
Чәмәк авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

04 декабрь 2021 ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 01 декабрендә 10 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде. " 2022 елда балигъ булган һәр гражданнан 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә риза буласызмы? Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлегенең Чәмәк авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүчеләрдән алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга:

а) Чәмәк авылына вак таш җәюгә.

«ӘЙЕ» «ЮК»

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия булган катнашучылар исемлегенә 15 (унбиш) катнашучы кертелгән, 8 кеше тавыш бирүдә катнашкан, бу 53,3% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча, гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә билгеләнде:
халык җыенында 7 (җиде) катнашучы «ӘЙЕ» позициясе өчен тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучы 1 (бер) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суксу авыл җирлегенең Чәмәк авылында халык җыены булып узды, Халык җыенының нәтиҗәләре гамәлдә дип таныргa.

2. 2022 елда үзара салым акчасын Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суксу авыл җирлегенең Чәмәк авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

а) Чәмәк авылына вак таш җәюгә.

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында

http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче Р.С.Низамиев